# Карендәшләр җыелган җирдә



Республика буйлап гөрләгән Питрау бәйрәме Чаллы шәһәрендә дә узды. 17 июль көнне бередә яшәүче керәшен карендәшләр шәһәрдәге яшел утрауга — Җиңү паркына бәйрәмгә җыелды.

Вакыт иртәрәк булуга да карамастан, халык инде шактый җыелган. Алар рәхәтләнеп очраша, аралаша, сөйләшеп сүзләре бетми. Шулай булмый соң, бер нәсел, бер тамыр кешеләре бит алар. Тагын кайчан әнә шулай җыеласың әле.

"Карендәшләр" керәшен фольклор ансамбле җырчысы Надежда Сырышева башкаруындагы "Ак балык" җыры яңгырый башлауга, халык сәхнәгә табарак якынайды. Аның "Бер карасаң, елар сәбәп тә юк" (К.Булатова сүзләре, Р.Андреев көе) җыры да, Геннадий Егоров белән башкарган нагайбәкләр җыры да тамашачы күңеленә хуш килде.

Әйтергә кирәк, шәһәр хакимиятенең физкультура, спорт һәм туризм идарәсе башлыгы урынбасары Райчка Ипеева җитәкләгән бу "Карендәшләр" ансамбленә гаять оста, талантлы җырчылар тупланган. Шуңадыр да шәһәркүләм үткәрелгән чараларда ансамбльнең үзенең йөзе, билгеле бер тоткан урыны бар. Ә бу Питрау бәйрәменә тулысы белән алар хуҗа дисәм дә, һич ялгыш булмастыр.

Питрау бәйрәме, әлбәттә, бәйге-уеннарсыз үтми. Быел да сәхнәгә чыгарып куелган кочак-кочак болын чәчәкләреннән, төрле үләннәрдән Питрау букеты да төзеделәр, хуш исле каеннан Питрау беркесе дә бәйләделәр. Ә Питрау чибәрләре исә җырда, биюдә, керәшенчә чигү конкурсларында сыналды. Питрау чибәре исеменә Алина Анисимова лаек булды.

Бөтен гомерен җыр сәнгатенә багышлаган, Татарстанның танылган җырчысы Раиса Тимофеева тамашачы өчен күптән көтелгән кунак иде. Ул, үзенә генә хас моңлы тавышы белән башкарып, берничә җыр бүләк итте.

Казан кунагы, җырчы Галина Казанцева, Чаллы композиторы һәм җырчысы Ринат Гобәйдуллинның, танылган җырчы Николай Храмовның, яшь башкаручылар Светлана Тимофеева белән Вера Васильеваларның чыгышлары зур алкышларга күмелде.

Ә җырчы, композитор Виталий Агапов һәм аның "Моңлы Чаллы" җыр театры бәйрәмгә тагын да зур җанланыш өстәде. Халык аяклары талганчы, рәхәтләнеп биеде, күңел ачты. Шәһәр өстенә әкренләп иңгән төн карасы да керәшеннәрнең күтәренке күңелен сүрелдерә алмады.



Бәйрәм барышында теләгән кешегә "Туганайлар" гәҗитенә язылу мөмкинлеге дә бар иде. Соңрак язылучылар арасында призлар уйнатылды һәм бәхетлеләр Питраудан бүләк белән кайтып китте.

Бу күңелле матур бәйрәмдә шәһәр хакиме урынбасары Р.Хәлимов, культура бүлеге начальнигы урынбасары З.Минһаҗева һәм башка кунаклар да катнашты.

**А.КЛИМОВА.**